| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель методического объединения | Заместитель директора по учебно-воспитательной работе | Директор МБОУ "Байрашевская ООШ" |
| ________________________ | ________________________ | ________________________ |
| Хайруллина Р.Ф.<br>протокол №1<br>от «19» августа 2025 г. | Платонова Г.С.<br>от «19» августа 2025 г. | Котдусова Г.Ю.<br>приказ №55 от «19» августа 2025 г. |

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00885CDF444F79C80D2D57428303A00130
Владелец: КОТДУСОВА ГУЛЬНАЗ ЮНУСОВНА
Действителен с 24.06.2024 до 17.09.2025

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Родная (татарская) литература»**

для обучающихся 5-9 классов

**с. Байрашево 2025 год**

## 5-9 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият» фәнен федераль белем бирү программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр

Туган (татар) телдәге әдәбият. 5 сыйныф: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 196 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 6 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 112 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 6 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 182 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 7 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 212 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 7 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 120 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 8 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 224 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 8 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 216 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 9 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 224 б.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 89 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 246 б.

### Аңлатма язуы

5-9 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият»ны өйрәнү башлангыч сыйныфларда алган белемнәрне тирәнәйтү, үстерүне, укучыларны татар халкының күп гасырлык әдәби, мәдәни мирасы белән таныштыруны күздә тота. Шул нигездә милли үзаңны үстерү, этник чыгышыңны аңлау, тарих, тел, мәдәният, дөньяга караш, менталитет, үз халкыңның фәлсәфи карашлары турында системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыруны, әдәбиятны сәнгатьнең бер төре буларак кабул итүне, форма һәм

эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып аның асылын аңлауны, шәрехли алуны, анализлау күнекмәләрен үстерүне тәэмин итә.

Укучыны халкыбызның мәдәни байлыгының зур бер өлешен тәшкил иткән әдәби мираска якынайту, андагы кыйммәтләрне аңлый, хөрмәт итә һәм куллана белергә, уку эшчәнлеген тормышта белем туплау, аны файдалана белергә өйрәтү уку предметының максат булып тора.

Уку предметын өйрәнүнең бурычлары:

– әдәби текстны шәрехләү, анализлау һәм аңлату күнекмәләрен үстерү;

– әдәби-теоретик төшенчәләр белән танышу, әдәби анализ алымнарын куллану аша укучыны сүз сәнгате булган туган телдәге татар әдәбиятына якынайту;

– татар әдәби барышы белән танышу һәм аның тарихи процесс белән бәйләнешен аңлау;

– укучыларның коммуникатив күнекмәләрен үстерү (татар телендә язма һәм телдән диалогик һәм монологик сөйләм);

– укучыларның күзаллауларын формалаштыру;

– укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру.

5-9 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы яңа ФДББСлары таләпләренә туры китереп эшләнелә. Ул ике дәрәҗәдә белем бирә торган мәктәп укучыларын күздә тота. Дәреслек татар телендә белем бирә торган һәм рус телендә белем бирүче мәктәпләрнең татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучыларына аталган. Шул ук вакытта яшь буынның туган телне белү, милли яшәешебез, халкыбызның гореф-гадәтәре белән танышлык дәрәҗәсе төрле булуы да исәпкә алынган. «Туган (татар) телдәге әдәбият» укучыны үз халкының яшәеш фәлсәфәсенә, тарихына, теленә дә якынайтырга, әдәбият фәне нигезләрен үзләштерүне дә тәэмин итәргә тиеш. Әмма укытуга бирелгән булган вакытның бик кыска булуы (атнага 1 сәгать) күләмле материалны бик тыгыз һәм аңлаешлы, гади итеп шул кысаларга сыйдыруны таләп итә. Шуны күздә тотып, уку материалын тәкъдим итүнең дә үзенчәлекле юллары сайланды.

Предмет халык авыз иҗаты әсәрләре (әкиятләр, мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар, бәетләр белән танышуны, татар әдәбияты барышын чорларга бүлеп өйрәнүне һәм татар әдәбиятын катлаулы гомуми әдәби процессның бер буыны буларак күзаллауны, әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерүне үз эченә ала. Әлеге материал укучының яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, башка предметлар белән дә бәйләнешне күздә тотып сыйныфларга өлешләп бүлеп бирелә.

5-7 сыйнфларда төп максат буларак әдәбиятның төр һәм жанр мәсьәләсен карау алга чыкты. Аерым алганда 5 сыйныфта игътибар үзәгендә әдәби төрләр белән танышу тора. Аерым әсәрләр мисалында проза, лирика, драма үзенчәлекләре өйрәнелә. 6 сыйныфта лирика, хикәя, повесть, лиро-эпик әсәрләрдә, драмада, фантастик һәм автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала. 7 сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен өйрәнәләр. 8 сыйныфта әдәби әсәрне укучылар сәнгати алымнарны карау ягыннан тикшерәләр. 9 сыйныф материалы алган белемнәрне системалаштыруны күздә тота. Ул тулы әдәбият тарихына күзәтү ясый. Әдәби барышны халык тарихы һәм гомуми әдәби процесс белән бәйләнештә

күзаллау мөмкинлеге тудыра. Сүз сәнгатенең кешенең рухи дөньясы белән тирәнтен керешкән төре булган әдәбиятны аңлап кабул итәргә өйрәтә.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

### 5 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мифлар (2 сәгать) |Ияләр – мифик образлар (Татар халык мифлары. «Җил иясе җил чыгара» мифы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп мифларны уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: мифларны һәм мифик образларны анализлау, мифларның тема һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү |
| | | Тавык турында да миф бар (Мифларның килеп чыгышы, аларны классификацияләү. «Тавык» мифы) | 1 | |
| **Халык авыз иҗаты** | | | | |
| 2 | Әкиятләр (5 сәгать) | Әкиятләрдә дә хакыйкать бар (Халык байлыгы буларак татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. «Хәйләкәр төлке» әкияте) | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Фольклор әсәре тексты белән эшләү: укыган әкиятнең эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, тексттагы вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әкиятләрне төрләргә аеру, халык әкиятләренә хас үзенчәлекләрне, сәнгати алымнары ачыклау; халык авыз иҗаты турында күзаллау формалаштыру, халык иҗаты әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау. |
| | | Кемнән үрнәк алырга? (Татар халык әкияте «Өч кыз») | 1 | |
| | | Каршына Ак бүре килеп чыккан... (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | |
| | | Тылсымның көче нәрсәдә? (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | |
| | | Әкияткә рәсем ясау җиңелме? (Проект эше: «Татар халык әкиятләренә рәсемнәр ясаучы рәссам-иллюстраторлар» / «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» альбомын төзү) | 1 | |
| 3 | Легендалар һәм риваятьләр (2 сәгать) | Хыял һәм чынбарлык (Татар халык легендалары. «Зөһрә кыз», «Кәккүк каян барлыкка килгән» легендалары) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп риваятьләрне һәм легендаларны уку.<br>Риваятьләр һәм легендаларның эчтәлеген сөйләү.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: сорауларга җаваплар бирү, тарихи вакыйгаларның һәм мифологик образларның легендаларда, риваятьләрдә ничек чагылуын һәм аларның вазифасын билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: легенда, риваять төшенчәләрен үзләштерү, риваять һәм легенда жанры үзенчәлекләрен билгеләү, риваятьләрнең легендалардан аермаларын ачыклау |
| | | Хәтер – киләчәк сакчысы (Риваятьләр. «Шәһәр нигә Казан дип аталган», «Тургай моңы» риваятьләре) | 1 | |
| 4 | Татар | Табышмак – тапкырлар уены | 1 | Тыңлау: сөйләмне ишетеп, тыңлап аңлау, |

<table>
<tr><td></td><td rowspan="4">халык авыз иҗатының кече жанрлары (4 сәгать)</td><td>(Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Табышмаклар)</td><td></td><td rowspan="4">таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау.<br>Фольклорның кече жанрларын һәм алар арасындагы аермаларны билгеләү.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: текстлардагы образлар системасы билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәр төшенчәләрен үзләштерү, мәкальләрнең, табышмакларның төп жанр үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Күнегү: мәкальләр һәм әйтемнәрне язма һәм телдән сөйләмдә куллану.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: контроль эшне башкару (тест)</td></tr>
<tr><td></td><td>Кемнең теленә сандугач кунган? (Мәкаль һәм әйтемнәр)</td><td>1</td></tr>
<tr><td></td><td>Әйтем – сөйләмнең бизәге, мәкаль – сөйләмнең җиләге (Мәкаль һәм әйтемнәр)</td><td>1</td></tr>
<tr><td></td><td>Үткән материалны кабатлау. Контроль эш.</td><td>1</td></tr>
<tr><td colspan="5">Татар әдәбияты</td></tr>
<tr><td rowspan="2">5</td><td rowspan="2">Әдәби әкият (автор әкияте) (2 сәгать)</td><td>Әкиятне кем иҗат итә? (Әдәби әкият. Г. Тукай «Шүрәле»)</td><td>1</td><td rowspan="2">Уку: әкиятләрне мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәренең тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып үз фикерләрен нигезләү.<br>Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау.<br>Текстны сөйләү: план буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әдәби әкиятнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, әдәби әкиятләрдәге халык авыз иҗаты традицияләрен, мотивларын, образларын ачыклау.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү</td></tr>
<tr><td>Матурлык һәм батырлык (Г. Тукайның «Шүрәле» әкияте)</td><td>1</td></tr>
<tr><td rowspan="6">6</td><td rowspan="6">Проза (6 сәгать)</td><td>Һәр гамәлнең эзе кала (Эпик әсәр үзенчәлекләре. Хикәя жанры. Ф. Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясе)</td><td>1</td><td rowspan="6">Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү.<br>Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Әсәр героена бәя: аның гамәлләрен бәяләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикәянең жанр үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу</td></tr>
<tr><td>Яхшылык итсәң үзеңә кайтыр (Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясе)</td><td>1</td></tr>
<tr><td>Кеше нинди була? (Дәрдемәнднең «Богдай» хикәясе)</td><td>1</td></tr>
<tr><td>Урман кызы ак томан сыман... (Г. Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе_</td><td>1</td></tr>
<tr><td>Күңелендә юкның күзе юк (Г. Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе)</td><td>1</td></tr>
<tr><td>Үткән теманы кабатлау. Иҗади эш: шәхси кичерешләргә нигезләнеп инша язу</td><td>1</td></tr>
</table>


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Мәсәл (2 сәгать) | Эш сөйгәнне ил сөя (Мәсәл жанры. Г. Тукай. «Умарта корты һәм чебеннәр») | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. Әсәр героена бәя. Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: мәсәлнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Яшь акылның тәҗрибәсе аз (Ә. Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәле) | 1 | |
| 8 | Лирик әсәрләр (8 сәгать) | Туган җирдә һәр нәрсә изге (Лирик әсәр үзенчәлекләре. Г. Тукай. «Пар ат») | 1 | Уку: шигырь текстын мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: укыган шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. Текстны сөйләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча сүзләр ярдәмендә сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм). Шигъри сөйләмнең чәчмә сөйләмнән аермасын билгеләү. Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Иҗади эш: рәсемгә карап хикәя төзү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Батырлыкка чәчәкләр дә баш ия (М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. «Кызыл ромашка» шигыре) | 1 | |
| | | Эшең калсын мең яшәрлек имән булып (М. Җәлилнең «Имән» шигыре) | 1 | |
| | | «Мин түз чүкмәм, катыйль, минең алда» М. Җәлил (Иҗади эш: Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзү) | 1 | |
| | | Дөнья кайчан матур? (М. Әгъләмов. «Матурлык минем белән», Г. Афзал «Матурлык эзлим») | 1 | |
| | | Балачак хыялы (Р. Миңнуллин. «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...») | 1 | |
| | | Дөреслек без күрә алганнан зуррак була аламы? ( Ш. Галиев. «Һәркем әйтә дөресен») | 1 | |
| | | Рәхмәтне саныйлармы? (Ш. Галиевнең «Тагын бер «рәхмәт» шигыре) Үткән теманы кабатлау | 1 | |
| 9 | Драма әсәрләре (2 сәгать) | Син әкият яратасыңмы? (Драма әсәрләре. Т. Миңнуллин. «Гафият турында әкият») | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку. Уку-укыту әңгәмәсе: укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, үз фикерен булдыру, сөйләү өчен мөстәкыйль рәвештә план төзү. Әдәби әсәрнең тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр геройлары турында фикер йөртү. Текстны сөйләү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: драма әсәренең жанр үзенчәлекләрен билгеләү. |
| | | Әкият хакыйкатькә якынайта (Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару. | 1 | Комплекслы кабатлау. Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү. Контроль тест биремнәрен үтәү. |

**6 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| **Кереш** | | | | |
| 1 | Гимн (1 сәгать) | Гимн. Россия гимны, Татарстан гимны. | 1 | Дәреслек белән танышу, аның белән эшләү тәртибен үзләштерү. Гимннарның текстын тыңлау һәм уку. Уку: интонация белдерү чараларын сайлау һәм куллану |
| **Татар халык авыз иҗаты** | | | | |
| 2 | Татар халык җырлары (3 сәгать) | Җыр – моң да, тарих та ул (Татар халык җырлары, аларны классификацияләү. Татар халык җыры «Иске кара урман») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укыган җыр текстларының эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, халык җырларына хас булган сәнгать алымнарын ачыклау. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау, җыр жанрының үзенчәлекләрен билгеләү. Проект эше: проект эшен башкару өчен материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, эшне башкару, чыгыш ясау. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Җыр – халкыбызның рухи юлдашы (Татар халык җырларының поэтик үзенчәлекләре. «Гөлҗамал», «Татарстан кызлары») | 1 | |
| | | «Җыр күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч» (Проект эшен яклау) | 1 | |
| **Татар әдәбияты** | | | | |
| 3 | Лирик әсәрдә образ тудыру алымнары (10 сәгать) | Иң изге хис – туган җиргә (Лирик әсәрдә образ. Р. Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан») | 1 | Уку: шигырьнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, үз карашын булдыру һәм башкалар әйткән фикерләрнең мәгънәләрен аңлау. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын текстан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. Тематикасы буенча якын шигырьләрне чагыштыру. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Иҗади эше: картина буенча сочинение язу. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү. |
| | | Тау башына салынгандыр безнең авыл (Г. Тукай. «Туган авыл») | 1 | |
| | | Туган җирнең төсе нинди? (Ф. Яруллин. «Туган ягы кирәк кешегә», Р. Вәлиева. «Гүзәл җирем») | 1 | |
| | | Кеше әйткән аваз, һәрбер сүз илаһи бит, изге (Дәрдемәнд. «Кил, өйрән», Р. Фәйзуллин. «Туган тел турында бер шигырь») | 1 | |
| | | Гимнга лаек һөнәрләр (Р. Фәйзуллин. «Гадиләргә гимн») | 1 | |
| | | Укытучы – һәркемнең юлдашы, һәр эшнең юл башы (Ф. Яруллин. «Сез иң гүзәл | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кеше икәнсез») | | Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Дәһшәтле утка керәмен... (Ф. Кәрим. «Ватаным өчен», «Сибәли дә сибәли») | 1 | |
| | | «Фашист самолеты очып үтте» (Иҗади эш: А. Пластовның «Пролетел фашистский самолет» («Фашист самолеты очып үтте») картинасы буенча инша) | 1 | |
| | | Бәлеш нинди хисне белдерә? (Ш. Галиев. «Пәрәмәч» («Перемяч») | 1 | |
| | | Иң матур хәтирә, иң якты хис (Һ. Такташ. «Әй, җырлыйсы килә шушы җырны») | 1 | |
| 4 | Фантастика әсәрләрендә образлар системасы (2 сәгать) | Хыял дөньясы чынбарлыкка якынмы? (Фантастика әсәрләрендә образлар системасы. К. Насыйриның «Әбугалисина» повесте) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру. Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү. Виртуаль экскурсиядә катнашу |
| | | Иң зур хезмәт – үз халкыңа хезмәт («Әбугалисина» повесте. К. Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты) | 1 | |
| 5 | Аллегорик образлылык (2 сәгать) | Кояшны капларлык ялган (Шартлылык һәм аллегорик образлылык. Г. Рәхим. «Яз әкиятләре») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, төп фикерен ачыклау, бер әсәрдәге капма-каршы холыклы геройларны чагыштыру. Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү. Виртуаль экскурсиядә катнашу |
| | | Нык ихтыярга күкләр буйсына (И. Гази. «Кояш артыннан киткән тургай») | 1 | |
| 6 | Автобиографик әсәрләрдә образлар системасы үзенчәлекләре (3 сәгать) | Үзем турында үзем (Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәр героена бәя бирү, сөйләмгә мөнәсәбәтен белдерү чараларын сайлау һәм куллану, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү. Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү. Хикәяләү: телдән сурәт тудыру. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Иң авыр һәм иң кадерле мизгелләр (Г. Тукай. «Исемдә калганнар» (өзек) | 1 | |
| | | Үткән теманы кабатлау. Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый (Иҗади эш: Л. Фәттаховның «Кечкенә Апуш һәм Сәгъди абзый» картинасы буенча сөйләм үстерү) | 1 | |
| 7 | Биографик әсәрләрдә образлар системасы (2 сәгать) | Шул вакытта мин китап алам (Ә. Фәйзинең «Тукай» романында образлылык тудыру чаралары) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру. Укыган әсәр проблемасын формалаштыру. Текстны сөйләү: кыскача һәм җентекләп сөйләү. |
| | | Җырлап торам, торган җирем тар булса да (Ә. Фәйзи. «Тукай») | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әңгәмәдә катнашу.<br>Текст буенча сораулар төзү |
| 8 | Хикәя һәм повесть жанрларында образлылык<br>(7 сәгать) | Бер мәхәббәтнең тарихы<br>(Г. Ибраһимованың тормыш юлы һәм иҗаты.<br>Г. Ибраһимов. «Алмачуар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, язучының тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматны да исәпкә алып укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу.<br>Әсәр героена бәя: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр ярдәмендә телдән геройның портретын тудыру, анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Хикәяләү: телдән сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм).<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Максатыңа ирешү бәхетле итәме? (Хикәя жанрында образлар системасы.<br>Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясе) | 1 | |
| | | Мәңгелек агышында Чишмә һәм Умырзая<br>(Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повестенда образлар системасы) | 1 | |
| | | Туган җирдә яшәү – зур бәхет<br>(Р. Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая» повесте) | 1 | |
| | | Матурлык – рухи халәт ул<br>(Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | |
| | | Хисләрнең дә үз йөзе, үз төс бар (Ә. Еники. «Матурлык») | 1 | |
| | | Намусыңны яшьтән ук сакла<br>(М. Галиев. «Җиңәсем килде»).<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 9 | Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы<br>(1 сәгать) | Батырлык кечкенә булмый<br>(Лиро-эпик әсәрләрдә образлар системасы.<br>М. Җәлил. «Сандугач һәм чишмә» балладасы) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, балладада хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү |
| 10 | Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре<br>(2 сәгать) | Сәхнә – тормышның көзгесе<br>(Драма әсәрләрендә образлар системасы үзенчәлекләре.<br>Г. Камал. «Беренче театр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын билгеләү, эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җаваплар бирү, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү: анализлау һәм әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү. |
| | | Биби күләме, көлдерәме?<br>(Көлкеле образлар тудыру алымнары. Г. Камалның «Беренче театр» комедиясе) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 11 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Нәтиҗәләр чыгару. Контроль эш. | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Үтелгәннәрне гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

**7 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре |
|---|---|---|---|---|
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Татар фольклорының оригиналь жанры – бәет (1 сәгать) | Шатлыкта – нур тама, кайгыда – моң ага (Татар халык авыз иҗаты жанры буларак бәет. «Сак-Сок бәете») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укылган бәетләр текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: бәет төшенчәсен үзләштерү, фольклор әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау |
| | | **Татар әдәбияты** | | |
| 2 | Хикәя жанры (4 сәгать) | Күңелендә буран купса... (Эпик жанр буларак хикәя. Ш. Камал. «Буранда») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү.<br>Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән геройның портретын тудыру.<br>Укыган әсәр проблемасын формалаштыру.<br>Текстны сөйләү: кыскача һәм җентекләп сөйләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Текст буенча сораулар төзү.<br>Хикәя язу алгоритмын ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү: хикәя жанрының үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш башкару: жанр үзенчәлеген исәпкә алып хикәя язу |
| | | Ана күңелен аңлау кирәк (Ш. Камалның «Буранда» хикәясендә ана образы) | 1 | |
| | | Сиреньнәр чәчәк аткан мәлдә (И. Гази. «Ак сирень») | 1 | |
| | | Хакыйкатьтән өстен көч юк (Р. Галиуллинның «Сәлам» хикәясе. Үткән материалны кабатлау) | 1 | |
| 3 | Повесть жанры (6 сәгать) | Җанга сеңгән бишек җылысы (Повесть жанры үзенчәлекләре. Г. Бәширов. «Туган ягым – яшел бишек») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, укыган әсәрнең темасын, идеясен билгеләү, проблемасын формалаштыру, әсәр исеменең мәгънәсен аңлау һәм аңлату.<br>Әсәр героена бәя бирү: автор тасвирламасы һәм сәнгати детальләр нигезендә телдән |
| | | Туган җир – тормыш мәктәбе (Г. Башировның «Туган ягым – яшел бишек» повесте) | 1 | |
| | | Халык күңеленә уелган бизәкләр | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | (Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестенда образлар системасы) | | геройның портретын тудыру.<br>Әсәр геройларына үз мөнәсәбәтен белдерү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Басулардан парта арасына кайтканда (М. Мәһдиевның «Без – кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | |
| | | Моң белән уралган истәлекләр (М. Мәһдиевның «Без – кырык беренче ел балалары» повесте) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш | 1 | |
| 4 | Роман жанры (4 сәгать) | Балачак хатирәләре (Роман жанры. И. Гази. «Онытылмас еллар») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген, әсәрнең темасын һәм идеясен билгеләү, тышкы кыяфәте, эчке сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Икмәктән дә кадерлерәк нәрсә була алмый (И. Газиның «Онытылмас еллар» романы) | 1 | |
| | | Җире барның җиме бар (И. Газиның «Онытылмас еллар» романының проблематикасы) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| **5** | Драма жанры (3 сәгать) | Яшәү яме нәрсәдә? (Драма жанры Т. Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр») | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку, рольләргә кереп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган пьеса текстының эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган текстның эчтәлеге буенча сораулар әзерләү, тышкы кыяфәте, эчке сыйфатлары, гамәлләре, башка геройлар белән мөнәсәбәтләреннән чыгып әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Рух нык җаннар бирешми (Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә көчле кеше образы) | 1 | |
| | | Кеше китә – җыры кала (Иҗади эш: «Кеше китә – җыры кала» темасына сочинение) | 1 | |
| 6 | Лирик жанрлар (12 сәгать) | Табигатькә таң калырлык (Лирика жанрлары. Пейзаж лирикасы. Г. Тукайның «Җәйге таң хатирәсе» шигырендә табигать образы) | 1 | Уку: шигырьләрнең мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: әсәрләрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәрнең эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрләрнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, сурәтләү һәм |
| | | Күңелдәге моңнар сүзгә күчә (М. Мирза. «Күздә | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бер мәл») | | лирик геройның хисләрен белдерү чараларын ачыклау, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Әдәби әсәрләренең эчтәлеге һәм проблемасы арасындагы бәйләнешне ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Галибәнә яктырып, әкрен генә ал таң ата» (Иҗади эш: «Галибәнә яктырып, әкрен генә ал таң ата» темасына сочинение) | 1 | |
| | | Йөрәк ярасын җылы куллар гына дәвалый (Күңел лирикасы. Х. Туфан. «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә хис-кичерешләр тирәнлеге) | 1 | |
| | | Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр нәрсә әйтер туганнарыма (Х. Туфан. «Агыла да болыт агыла») | 1 | |
| | | Яшьлек эзләре калган үзән (С. Хәкимнең «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре) | 1 | |
| | | Байлык белән бәяләнми гомер (Фәлсәфи лирика. Р. Фәйзуллин «...Җыя кеше», М. Мирза. «Моң») | 1 | |
| | | Үткәннәребез бай, киләчәгебез өметле (Гражданлык лирикасы. Г. Афзал. «Бу Ватан», Н. Арсланов. «Халкыма») | 1 | |
| | | Утта янмый, суда батмый безнең үткәннәр (Р. Гаташ. «Татар китабы») | 1 | |
| | | Йөз матурлыгы күзгә өчен... (Р. Харис. «Кеше кайчан матур») | 1 | |
| | | Кеше кайчан матур була (Проект эше яклау) | 1 | |
| | | Туган телне сайлап алмыйлар (Г. Морат. «Туган тел» («Родной язык»).<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| **7** | Поэма жанры (2 сәгать) | Моң чишмәсе кайдан башлана (Әдәбиятның лиро-эпик жанрлары. Поэма жанры. Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | Уку: поэманың мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, лирик |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Халык белән мәңге бергә (Р. Фәйзуллин. «Сәйдәш») | 1 | геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Хикәяләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча тасвирлап сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Музейга виртуаль экскурсиядә катнашу |
| 8 | Нәсер жанры (1 сәгать) | Ерагайган саен ара, сагыну арта бара (Нәсер жанры үзенчәлекләре. Г. Кутуйның «Сагыну нәсере») | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү, нәсердә хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| 9 | Нәтиҗәләр чыгару | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү |

**8 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| | | **Халык авыз иҗаты** | | |
| 1 | Халык авыз иҗаты. Дастаннар (4 сәгать) | Халык авыз иҗаты буларак дастаннар. «Идегәй» – тарихи дастан. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: укыган текстның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, әсәрнең сюжет һәм композиция үзенчәлекләрен бәяләү.<br>Уку әңгәмәсе: укылган әсәр эчтәлегенә нигезләнеп әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне формалаштыру һәм аны нигезли һәм яклый алу, дастан жанрына хас үзенчәлекләрне билгеләү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау |
| | | Идел йортның улы Идегәй кем ул? («Идегәй» дастанында образлар системасы) | 1 | |
| | | Әдәм гарибә шул булыр —<br>Кайтып илен тапмаса! («Идегәй» дастанының идеясе һәм аның сәнгатьчә гәүдәләнеше) | 1 | |
| | | И, Идел йорт, Идел йорт (Проект эше яклау) | 1 | |
| | | **Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Әдәби әсәрдә сәнгати алым. Пейзаж (5 сәгать) | Таш кайчан телгә килә? (Әдәби алым буларак пейзажның әсәрдәге роле) | 1 | Уку: текстны аңлап, сәнгатьле уку. Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әсәрнең темасын һәм проблемасын билгеләү, әсәрнең идеясен формалаштыру. Текстны сөйләү: иҗади сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Җидегән чишмә нәрсә турында җырлый? (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романының идеясен ачуда пейзажның роле) | 1 | |
| | | Табигать-ананың сулышын тоеп (Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында пейзаж сурәтләнеше ярдәмендә татар халкының рухи байлыгын ачу) | 1 | |
| | | Нинди ул Агыйдел кызы? (Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим» повестенда яшьлек, мәхәббәт һәм табигать параллельлеге) | 1 | |
| | | Күңелеңә сандугач керсә... (Лирик әсәрләрдә пейзажның үзенчәлеге: Н. Арслановның «Яз» шигыре) | 1 | |
| 3 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Портрет (6 сәгать) | Сәнгати алым буларак әдәби әсәрдә портрет бирелеше | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку. Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү. Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Гасырлар аша күз салып (Тарихи әсәрләрдә портрет бирү үзенчәлеге. Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» әсәре мисалында) | 1 | |
| | | Һәр хиснең үз йөзе бар (Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» әсәрендә портрет геройның эчке дөньясын ачу чарасы) | 1 | |
| | | Хисләр һәм акыл каршылыгы (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә психологик портрет тудыру үзенчәлеге) | 1 | |
| | | Рухи халәтнең тышкы чагылышы нинди? (Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә чагыштырма портрет) | 1 | |
| | | Үзе уңган, үзе тыйнак – татар кызы ... (Ш. Җиһангированың | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «Татар кызы» шигырендә милли портрет бирелеше) | | |
| 4 | Әдәби әсәрдә сәнгати алымнар. Әдәби деталь (әйберләр дөньясы) (5 сәгать) | Кульъяулыгым – вәгъдә билгесе (Сәнгати алым буларак әдәби деталь, әйберләр дөньясы) | 1 | Уку: текстның мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. Әдәби әсәр тексты белән эш: әсәрнең темасын, идеясен һәм проблемасын билгеләү, әсәр геройларына карата үз мөнәсәбәтеңне анализлау һәм белдерү. Текстны сөйләп бирү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Йөрәк түрендәге хисләр (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әдәби детальнең психологик төрләре) | 1 | |
| | | Хәситәме, камчымы?.. (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә әйберләр дөньясының әсәр идеясен ачудагы роле) | 1 | |
| | | Үткәннәрне чүплеккә салып булмый (Н. Думавиның «Яшь ана» әсәрендә геройларның күңел халәтен ачуда әдәби детальнең әһәмияте) | 1 | |
| | | Сары – сагыш билгесе (Лирик әсәрләрдә әдәби деталь: Х. Туфанның «Каеннар сары иде» шигыре) | 1 | |
| 5 | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре (4 сәгать) | Символизм. Әдәби әсәрдә символларның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәренең тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып үз фикерләрен нигезләү. Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройны тасвирлау. Декламацияләү:текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Язмыш сынавын һәркем үзенчә кичерә (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда кеше язмышы, рухи батырлык мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Җилкәнеңне җилләр екса (Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда герой характерын ачарга ярдәм иткән символлар) | 1 | |
| | | Шигъриятнең серле дөньясы (Шигърияттә символизм: Дәрдемәнднең «Кораб», Роб. Әхмәтҗанов «Гомер китабы» шигырьләре) | 1 | |
| 6 | Психологизм. Әдәби әсәрләрдә психологизм алымнары (4 сәгать) | Психологизм. Әдәби әсәрдә психологизмның төрләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын |
| | | Тән ярасын оныттырырлык моң (Ә. Еникинең «Кем | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җырлады» әсәрендә психологизм аша геройның рухи халәтен ачу) | | билгеләү.<br>Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: психологизм үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Күңел кошың күкрәгеңә сыймаса... (Г. Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» әсәрендә геройлар омтылган шәхес иреге) | 1 | |
| | | Хыял һәм хакыйкатьнең арасы еракмы? (Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында хатын-кыз психологиясе) | 1 | |
| 7 | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп). Хронотопик образлар<br>(5 сәгать) | Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (Лирик әсәрләрдә хронотоп бирелеше: М. Галиев «Кичке сурәт») | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әсәр героена бәя.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хронотоп төшенчәсен ачыклау |
| | | Рухи ныклык кайдан килә? (Г. Исхакыйның «Көз» повестенда урын һәм вакыт бердәмлеге) | 1 | |
| | | Гомер көзенең җимешләре татлы булсын дисәң... (Г. Исхакыйның «Көз» әсәрендә геройлар язмышына мөнәсәбәтле хронотопик образлар) | 1 | |
| | | Җырга тиң мәхәббәт (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда хронотоп бирелеше) | 1 | |
| | | Гаилә – тигез хокуклы кешеләр союзы ул (Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда геройлар язмышын ачарга ярдәм итүче хронотопик образлар) | 1 | |
| 8 | Нәтиҗәләр чыгару<br>(1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау.<br>Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплексłы кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү |

**9 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| **Кереш** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сүз сәнгате буларак әдәбият. Әдәбиятны чорларга бүлү (1 сәгать) | Татар әдәбиятын чорларга бүлү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, тема буенча сорауларга җаваплар, үз фикереңне формалаштыру, башкалар фикерләренең мәгънәсен аңлау. Материалны структуралаштыру, системалаштыру, классификацияләү, гомумиләштерү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| **Татар әдәбияты тарихы** | | | | |
| 2 | Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты (2 сәгать) | «Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди...» (Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына гомуми күзәтү. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган поэманың эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең темасын, идеясен, проблемаларын ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне табу, поэманың төп героена бәя бирү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Камиллеккә ирешү җиңелме? (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанында гомумкешелек идеаллары чагылышы) | 1 | |
| 3 | XIII-XVгасыр әдәбияты (2 сәгать) | Алтын Урда чоры әдәбияты үзенчәлекләре | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау, эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру, әсәрләрнең тел үзенчәлекләрен ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү. Әдәби әсәрне интерпретацияләү. Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү. Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Мәхәббәт – иң саф хис (С. Сараи. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасының идея-эстетик эшләнеше) | 1 | |
| 4 | Казан ханлыгы чоры әдәбияты (1 сәгать ) | Казан ханлыгы чоры әдәбияты. Кол Шәриф «Гафил торма». Үткән материалны кабатлау. | 1 | Уку: әсәрне сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, әсәрләрнең идея эчтәлеген ачыклау, текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү. Әдәби әсәрне интерпретацияләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү. Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| 5 | XVII гасыр әдәбияты. (2 сәгать) | XII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, текст буенча сораулар төзү, укылган текст буенча |
| | | Әхлак һәр чор өчен олы | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кыйммәт (М. Колый хикмәтләрендә әхлакый кануннар чагылышы) | | әңгәмәдә катнашу, укылган текст эчтәлеге нигезендә үз карашын формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикмәт жанрының үзенчәлекләрен билгеләү |
| 6 | XVIII гасыр әдәбияты (2 сәгать) | XVIII гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, аның нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Энциклопедик мирас калдырган әдип (Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты) | 1 | |
| 7 | XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте (4 сәгать) | XIX гасыр әдәбиятына гомуми күзәтү. Мәгърифәтчелек хәрәкәте | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: язучының биографиясе белән танышу, әһәмиятле вакыйгаларны билгеләү, тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укылган әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эш: сюжет һәм композиция төзелешендәге үзенчәлекләрне тасвирлап бирү, әдәби әсәрдә вакыйгалар үстерелеше этабын табу, әсәрнең төп героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча кыскача сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Дөньяви хисләр җырчысы. (Г. Кандалый иҗаты. «Сәхипҗәмал» поэмасы) | 1 | |
| | | Татар халкының олуг шәхесе (Каюм Насыйри эшчәнлеге. «Кырык бакча» хикәяләре) | 1 | |
| | | Гыйлемлек – бәхет ачкычы (М. Акъегетзадә «Хисаметдин менла» повестенда заман герое) | 1 | |
| 8 | XX гасыр башы әдәбияты (9 сәгать) | XX гасыр башы әдәбиятына гомуми күзәтү. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрдә геройларның позицияләрен аеру, |
| | | «Әйдә, халыкка хезмәткә...» (Г. Тукай эшчәнлеге һәм иҗаты. «Милләткә», «Милли моңнар» шигырьләре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Гөрләгән сулар ни сөйли? (Дәрдемәнд (Закир Рәмиевнең) тормышы һәм иҗаты. «Видагъ» «Гөрләгән сулар» шигырьләре) | 1 | укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстгагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш башкару: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү. |
| | | Милләтнең таңы кайчан атар? (С. Рәмиев тормышы һәм иҗаты. «Таң вакыты», «Мин» шигырьләре) | 1 | |
| | | Хатын-кыз – милли яшәеш сакчысы (Г. Исхакый тормышы һәм иҗаты. «Сөннәтче бабай» хикәясе) | 1 | |
| | | Татар тормышын яңарышка әйдәүче әдип (Ф. Әмирхан тормышы һәм иҗаты. «Хәят» повесте) | 1 | |
| | | Хәятнең гүзәл хәяте (Ф. Әмирханның «Хәят» повесте) | 1 | |
| | | Хыял иркендә чәчәк аткан мәхәббәт (М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы) | 1 | |
| | | Саф хисләр акчага сатылмый.<br>(М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы).<br>Үткән материалны кабатлау | 1 | |
| 9 | 1920-1930 еллар әдәбияты<br>(1 сәгать) | 1920-1930 еллар әдәбиятына гомуми күзәтү. Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, әсәрнең төп фикерен ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройга бәя бирү, автор позициясен ачыклау, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстгагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Иҗади эш: сочинение язу |
| 10 | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты (1941-1945 еллар)<br>(2 сәгать) | Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятына гомуми күзәтү (М. Җәлил иҗаты. «Моабит дәфтәрләре»: «Җырларым», «Кичер, илем» шигырьләре) | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Уку: әсәрләрне сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, лирик геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне автор фикерен сәнгатьчә җиткерүе буларак кабул итү.<br>Хикәяләү: укылган әсәр эпизодлары һәм өлешләре буенча тасвирлап сөйләү (сүз белән сурәт тудыру).<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Үткән материалны ныгыту: сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Шагыйрь һәм яугир язмышы (Ф. Карим иҗаты. «Кыр казы» шигыре) | 1 | |
| 11 | 1960-1980 еллар әдәбияты<br>(1 сәгать) | 1960 – 1980 еллар прозасына гомуми күзәтү | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм текстагы әһәмиятен билгеләү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен материал җыю һәм системалаштыру, фикер алышу, проект эшен башкару, телдән чыгыш ясау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Илгә килгәнне иңең белән күтәр (А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте) | 1 | |
| 12 | 1960-1980 еллар шигърияте | 1960-1980 еллар шигъриятенә күзәтү. | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү, язучының |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (2 сәгать) | Гамьле дөнья тудырган хисләр ташкыны (Р. Фәйзуллинның «Нюанслар иле»: «Чынлык», «Вакыт», «Көзге яңгыр», «Язгы кәеф», Р. Харисның «Ак сөлге», И. Юзеевнең «Калдыр, аккош, каурыеңны» шигырьләре) | 1 | биографиясе белән танышу.<br>Әсәрләрне уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Телдән сөйләү өчен тезис план төзү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Декламацияләү: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| 13 | 1960-1980 еллар драматургиясе<br>(2 сәгать) | 1960-1980 еллар драматургиясе. Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасы. | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу |
| | | Әкият эченә яшерелгән хакыйкать<br>(Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасында җәмгыятькә тәнкыйди караш) | 1 | |
| 14 | XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар әдәбияты<br>(1 сәгать) | Янып калсын гомереӊ маяк булып... М. Җәлил (Р. Миннуллинның «Һәйкәлләрне тыңлыйк!», И. Ихсанованың «Кеше булса…» шигырьләре) | 1 | Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү.<br>Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әңгәмәдә катнашу.<br>Үткән материалны ныгыту: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү |
| 15 | Хәзерге татар әдәбияты (1 сәгать) | Күктә кояш балкып-балкып яна (А. Әхмәтгалиева. «Кайтаваз»; Р. Мөхәммәтшин. «Август азагы», «Күктә кояш балкып-балкып яна») | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Уку әңгәмәсе: тарихи-әдәби барышның төп этапларын аерып күрсәтү. Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, укыган әсәрнең сюжетын темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын текстан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү |
| 16 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплекслы кабатлау. Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү. Контроль тест биремнәрен үтәү |

Лист согласования к документу № 100 от 04.09.2025
Инициатор согласования: Котдусова Г.Ю. Директор
Согласование инициировано: 04.09.2025 18:17

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Котдусова Г.Ю. | | Подписано 04.09.2025 - 18:17 | - |